**Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение**
**«Сарсаз-Багряжская основная общеобразовательная школа»**
**Заинского муниципального района Республики Татарстан**
**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**муниципаль бюджет учреждениесенең**
**“Сарсаз-Баграж төп гомуми белем мәктәбе”**

**IX Республиканский конкурс экологической социальной рекламы**
**«Город под защитой детства»**
Номинация:
**«Экологическое эссе»**

# Туган җиребезне саклыйк!

Зәй районы Сарсаз – Баграж
төп гомуми белем мәктәбенең
8 сыйныф укучысы
Мартемьянова Юлиянең эше
Фәнни җитәкчесе: татар теле һәм әдәбияты
укытучысы Чернова И.Г.

2021ел

XX гасыр ахырында кешелек дөньясы алдына Җирдәге бөтен тереклек юк ителү куркынычы килеп басты. Кешелекнең табигать белән бәйләнеше – хәзерге заманның актуаль мәсьәләләренең берсе булып санала. Хәзерге заман экологиясенең үсеше әйләнә-тирәне фәнни яктан танып-белүгә зур йогынты ясый. Тормышыбызны һәрьяклы демократияләштерү, экономик реформаларны тирәнәйтү җәмгыятьтә кешенең табигатькә карашын үзгәртә, аның экологик ихтыяҗларын экономикага булган таләпләре белән беррәттән куя һәм кешедә табигатькә, әйләнә-тирә мохиткә карата җаваплылык хисен үстерә һәм арттыра.

Ә нәрсә соң ул Экология? Экология фәне – белемнәр системасы ул. Аны өйрәнү биләмәсе искиткеч зур, мөгаен, чиге дә юктыр. Нибары 20 – 25 ел эчендә экологиянең әһәмияте бик югары күтәрелде. Бу фән кешелек дөньясын саклауга хезмәт итә.

Үзен – “табигать патшасы” дип исәпләгән адәм баласының эшчәнлеге һәрчак уңай нәтиҗәләр бирми. Киресенчә, ул күп очракларда табигать анабызга фаҗигале үзгәрешләр алып килә, әйләнә-тирәбезгә күпме зыян салды һәм сала. Күп сулы елгаларыбыз саега, җирләр упкынсыман ярыклар белән яргалана. Елга үзәннәре баткаклыкка әйләнә, пычрана. Эчәр суларыбыз, сулар һавабыз көннән-көн шакшылана бара. Иген үстерелә торган уңдырышлы җирләр чикләнә.

Минемчә, һәр кеше табигатьнең искиткеч гүзәллеген  кече яшьтән үк күрергә, тормышка сөенергә өйрәнергә тиеш. Табигать – кеше тәрбияләүнең бай чыганагы. Ләкин табигатьне танып-белүдән акыл, хисләр, карашлар формалашуы бары тик башлана гына әле.

Табигать бездән ярдәм көтә. Аның матурлыгы һәм байлыгы безнең кулда. Табигатьне саклау өчен без үз бурычыбызны үтәргә тиеш. Табигатьне саклау – үзебезне, киләчәгебезне, өебезне саклау дигән сүз. Яшәү мәгънәсе ул - табигать белән бергә булуда, үзебездән соң лаеклы алмаш – табигатьнең ышанычлы ярдәмчеләрен тәрбияләп калдырудан тора.